| СОВЕТ<br>ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|---|

| **РЕШЕНИЕ**<br>**30.05.2024** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 158** |
|---|---|---|

Зеленодольск шәһәре Советының 2021 елның 24 мартындагы 38 номерлы карары белән расланган Зеленодольск шәһәре Советы депутаты статусы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (Зеленодольск шәһәре Советының 2021 елның 26 августындагы 59 номерлы, 2023 елның 30 мартындагы 113 номерлы карарына кертелгән үзгәрешләр белән)

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законга, 2004 елның 24 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына, Зеленодольск шәһәре Советы Регламентына туры китереп, Зеленодольск шәһәре Советы **карар кылды:**

Зеленодольск шәһәре Советының 2021 елның 24 мартындагы 38 номерлы карары белән расланган Зеленодольск шәһәре Советы депутаты статусы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә (Зеленодольск шәһәре Советының 2021 елның 26 августындагы 59 номерлы, 2023 елның 30 мартындагы 113 номерлы карарына кертелгән үзгәрешләр белән):

1.1. 2 статьясының 2 өлеше 2 пунктының «а» пунктчасында «, җирлек сайлау комиссиясе аппаратында» төшереп калдырырга;

1.2. 2 статьясының 2 өлеше 2 пунктының «б» пунктчасында, « ,җирлек сайлау комиссиясе аппаратында» төшереп калдырырга;

1.3. бишенче статьяны түбәндәге эчтәлектәге 2.1 өлеш белән тулыландырырга:

«2.1. Коррупциягә каршы тору максатында, 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгәне һәм бурычларны үтәмәгәне өчен, әгәр мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү, шулай ук мондый бурычларны үтәмәү күрсәтелгән затларга 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы көрәш турында» 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 3 - 6 өлешләрендә каралган тәртиптә бәйле булмаган хәлләрнең нәтиҗәсе дип танылса, депутат җаваплылыктан азат ителә».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында(http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы

Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

**Зеленодольск шәһәре Мэры,**
**Советы рәисе** **М. П. Афанасьев**